**ГЛАВА ЕГОРЬЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422621д. Каипы,
ул. Центральная, д.50
тел: 3-36-19

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЕГОРЬЕВО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422621Каипы авылы,
Эзек урамы, 50 нчы йорт,
тел: 3-36-19

**2021елның 16 ноябре** **12 номер**

# КАРАР

**Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлеге Бима авылында урнашкан кадастр номерлары 16:24:070801:2177, 16:24:070801:2176 булган җир кишәрлекләре территорияләрен планлаштыру һәм ызанлау проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьев авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2019 елның 11 февралендәге 96-РС номерлы үзгәрешләр белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2018 елның 12 ноябрендәге 61-РС номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә халык тыңлауларын (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә таянып, территорияләрнең тотрыклы үсешен тәэмин итү, шул исәптән планлаштыру структурасы элементларын аерып чыгару, җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү, капиталь төзелеш объектларын планлаштырып урнаштыру зоналары чикләрен билгеләү максатларында, карар бирәм:

1. Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлеге Бима авылында урнашкан кадастр номерлары 16:24:070801:2176; 16:24:070801:2177булган җир участокларын планлаштыру һәм ызанлау проектын эшләү буенча гавами тыңлаулар билгеләргә;

2. Гавами тыңлаулар уздыру чорын - кызыксынучы затларга гавами тыңлаулар уздыру турында хәбәр итү мизгеленнән алып гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр билгеләргә. Гавами тыңлаулар үткәрү срогы кимендә бер айдан ким ике айдан артык була алмый;

3. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево авыл җирлеге Башкарма комитетына:

3.1. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында каралган гавами тыңлауларның башлануы турында хәбәр әзерләргә;

3.2. Әлеге карар үз көченә кергән көннән алып 14 эш көне эчендә әлеге карарның 3.1 п. күрсәтелгән хәбәрнамәне җирлек уставында билгеләнгән тәртип нигезендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) кирәк.;

3.3. Әлеге карарның 2 пунктында күрсәтелгән чорда гавами тыңлаулар уздырырга;

3.4. Территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектын, гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне, гавами тыңлаулар тәмамланганнан соң 5 көн эчендә, ахыргы карарны кабул итү өчен Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрергә.

4. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Егорьево рәсми сайтында- https://laishevo.tatarstan.ru/egorevskoe-selskoe-poselenie.htm. веб-адресы буенча, норматив-хокук документлары бүлегендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Егорьево авыл җирлеге Советы рәисе** **Р.Ж.Хәмидуллин**